РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА БУРМЕТЬЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КИЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | Киекле ав. | КАРАР

«02» ноябрь 2020 ел | № 2

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Кизләү авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2020 елның 19 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Кизләү авылы, Клуб урамы, 3нче йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Кизләү авылында Клуб, Тынычлык, Яр буе, Привольная, Тимур, А. Халиков урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2020 елның 19 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Кизләү авылы, Терлекчеләр урамы, 29нчы йорт адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Кизләү авылында Терлекчелер, Күпер урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.
3. 2020 елның 19 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Кизләү авылы, Спорт урамы, 19 йорт адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Кизләү авылында Интернационал, Бакча, Спорт, Чирмешән, Шоссе урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.
4. 2020 елның 24 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка Кизләү авылы, Клуб урамы 3нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Кизләү авылында Татарстан, Октябрь, Пионер, Почта, Мәктәп, Октябрь-Пионер, Почта тыкрыгы урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.
5. Кизләү авылында яшәүчеләрнең исемлеген гражданнар җыенын үткәрү өчен сайлау тәртибен территориаль билге буенча эшләргә.
6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитет тарафыннан башкарыла.
7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

«Киекле авыл җирлегенең Кизләү авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан кала, балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Кизләү авылында су җыю скважиналарын карап тоту өчен, эшләр һәм хезмәтләр башкару, товарлар сатып алу.

Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән Кизләү авылы территориясендәге юлларны сезонлы карап тоту, юл кырыйларына таш, ватылган кирпеч, грунт, вак таш, ком түшәү (сатып алу, ташу, җәю).

Кизләү авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу.

Кизләү авылы зиратын төзекләндерү һәм сезонлы карап тоту (коймаларны ремонтлау, агачларны кисү, үлән чабу).

Кизләү авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр, товарлар сатып алу (янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру, урнаштырылган гидрантларны ремонтлау).

Кизләү авылында спорт-массакүләм һәм мәдәни-массакүләм чараларны оештыру һәм үткәрү

«РИЗА» «КАРШЫ»

10. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кизләү авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

11. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Киекле авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.Ә.Заһертдинова